КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

2017 ел, 21 март

№ 174

г. Казань

«9 нчы балалар стоматология поликлиникасы» акционер җәмгыятен төзү турында

Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен нәтиҗәле куллану максатында Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының гамәлгә кую юлы белән, җәмгыятьнең устав капиталында Татарстан Республикасы өлешен кимендә 25 процентка плюс бер акция тәэмин итү шартында «9 нчы балалар стоматология поликлиникасы» акционер җәмгыятен төзү турында тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына:

төзелә торган акционер җәмгыятьнең устав капиталына Татарстан Республикасы исеменнән Татарстан Республикасы (Татарстан), Казан шәһәре, Ямашев урамы, 52 йорт адресы буенча урнашкан 16:50:110417:8949 кадастр санлы 1 399 кв.метр гомуми мәйдандагы беренче каттагы 1 – 34, 3а, 7а, 12а санлы, цоколь каттагы 1 – 22, 38 санлы торак булмаган бүлмәләрне һәм күчмә мөлкәтне кертергә;

Россия Федерациясендә бәяләү эшчәнлеген җайга салучы законнар таләпләре нигезендә төзелә торган «9 нчы балалар стоматология поликлиникасы» акционер җәмгыяте устав капиталына Татарстан Республикасы исеменнән кертелә торган дәүләт мөлкәтен бәяләүне тәэмин итәргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\174.docx